ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«5» 11 2019 г. № 245

**Татарстан Республикасының Балтач район Советында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, шулай ук, гражданнарның җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр, гариза, шикаятьләр белән мөрәҗәгать итү конституцион хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. 2009 елның 18 мартындагы 70 нче карар белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район Советында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибенең 3.4 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

«Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу очраклары турында мәгълүмат булган язма мөрәҗәгать, теркәлгән көннән алып биш көн эчендә эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органына һәм Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә), әлеге Тәртипнең 3.14 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш, мөрәҗәгать җибәргән гражданга аның мөрәҗәгатен яңадан күчерү турында хәбәрнамә юллап җибәрелә.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Балтач муниципаль районы башлыгы Р.Р.Нотфуллин